**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль район Советы**

Азнакай шәһәре №132-32 «22» апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар хисабына тормышка ашырыла торган чыгымнарның юнәлеше турында

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатыннан һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының _____ 2019 ел №___карары нигезендә «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында»гы карары нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы **карар чыгарды:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлеше нигезендә шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http:// aznakyevo.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай шәһәре Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Башлык М.З.Шәйдуллин